**Салахова Р.Р.**

Казан, Россия

# “Биология” белгечлеген үзләштерүче студентларга татар телен укыту үзенчәлекләре

Бүгенге мәгариф системасында вариативлык принцибы киң җәелә бара. Бу исә уку йортлары педагогик коллективларына педагогик процессны теләсә кайсы модель (автор программалары) буенча да сайлап алырга һәм конструкцияләргә мөмкинлек тудыра. Мәгарифнең алга таба үсеше нәкъ менә шушы юнәлештә алып барыла: аның эчтәлегенең төрле вариантлары төзелә; мәгариф структураларының нәтиҗәлелеген арттыруда хәзерге заман дидактикасының мөмкинлекләре файдаланыла; яңа идея һәм технологияләр фәнни һәм гамәли нигезләнә. Кулланылыш сферасына заманның иң алгарышлы технологияләре кергән саен, телләрне өйрәнүгә дә ихтыяҗ арта. Урта һәм югары һөнәри белем бирү уку йортларының төп максаты - икетеллелек һәм күптеллелек шартларында эшләргә сәләтле иң югары дәрәҗәдәге белгечләр әзерләп чыгару.

Телгә өйрәнү – ул тел турында кагыйдәләр өйрәнү генә түгел. Телгә өйрәтү – сөйләм эшчәнлегенең һәрбер төренә - сөйләшергә, тыңлап аңларга, укырга, язарга өйрәтүне күз алдында тотарга тиеш. Ә инде сөйләм эшчәнлегенең югарыда санап үтелгән төрләренең укучы үзләштерә торган белгечлек белән бәйле булуы, беренчедән, телгә карата кызыксынуны арттырса, икенчедән, студентка үз һөнәре буенча алган белемнәрен тагын да баету мөмкинлеге тудыра. Мәсәлән, “Биология” белгечлеген үзләштерүче студентларга татар теле дәресләрендә тәрҗемә итү белән бәйле булган биремнәр өчен хәзерге биология фәненең төп тармаклары булган ботаника, зоология, анотомия, физиология, цитология, генетика, биохимия, эмбриология, биогеография, биотехнология өлкәсен яктырткан текстлар тәкъдим итәргә мөмкин.

Телне өйрәнү – билгеле бер күләмдәге тел материалын, ягъни фонетик, лексик, грамматик материалны өйрәнү дигән сүз. Ләкин чит ил телен өйрәнү шактый кыен, һәм моңа бирелгән вакытның чикле икәнен истә тотып, иң башлап лексик, фонетик, грамматик минимумнар билгелиләр: укучы билгеле бер күләмдә сүзләр, аваз күренешләре, грамматик кагыйдәләр өйрәнергә һәм истә калдырырга тиеш була. Моның өчен шулай ук белгечлек белән бәйле булган текст эчендәге сүзләрдән отышлы файдаланырга мөмкин. Мәсәлән:

1.Текстны укыгыз, русчага тәрҗемә итегез;

2. Татар теленә генә хас аваз кергән сүзләрне дәфтәрләрегезгә язып алыгыз, аларны дөрес әйтергә өйрәнегез;

3. Калын яки нечкә сузыклардан гына торган өчәр сүз язып алыгыз һәм алар белән яңа җөмләләр төзегез.

4. Текст ярдәмендә сорау кисәкчәләре һәм “әйе”, “юк” сүзләрен кулланып диалог төзегез, диалогны тиешле интонация белән укыгыз.

5. Асларына сызылган сүзләр турында ниләр беләсез?

6. Тексттан *әйт, күр, очра, яшә, аша, кер* фигыльләре кергән җөмләләрне табыгыз, аларны юклык формасына куеп, җөмләне яңадан укып карагыз.

Коңгыз кебек кара дип еш әйтәләр. Чыннан да, коңгызларның каралары күп. Ләкин барысы да кара түгел. Кызыл, зәңгәр, куе зәңгәр, яшел, сары, хәтта көмеш һәм алтын төсендәге коңгызлар да була. Буйлары 15 см га җитә торган бик зур коңгызлар, зурайткыч пыяла аша карагач кына күренә торган бик кечкенә коңгызлар бар. Коңгызларны һәркайда – дөньяның теләсә кайсы җирендә, теләсә кайсы географик зонада – тауда, чүлдә, тайгада һәм суда очратырга мөмкин. Алар бик күп. Безнең илдә генә дә аларның 25 меңгә якын төре яши. Коңгызлар бер-берсеннән зурлыклары һәм төсләре ягыннан гына түгел, яшәү рәвешләре һәм гадәтләре белән дә аерыла. Аларның бер ишесе – ерткыч, икенчеләре үсемлек белән туена, өченчеләре үлгән хайваннарны ашый. Әмма шундый аерымлыкларына карамастан, барлык коңгызлар үзара бер төркемгә - отрядка керәләр. Аларның уртак билгесе – канатлары төзелешендәге охшашлык.

Биология белгечлеген үзләштерүче студентларга татар теле дәресләрендә биологик терминнарның татарча-русча атамаларын өйрәтүгә дә зур игътибар бирелергә тиеш. Биология фәннәре системасына караган күп санлы терминнарның ике телдә янгырашын өйрәнү студентларга фәнни планда гына түгел, гомумән, дөньяны танып белү юнәлешендә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәчәк. Түбәндәге эш төрләре шул максаттан чыгып тәкъдим ителә.

1. Биологик терминнарның татарча вариантларын язып чыгыгыз.

*Цапля. сурок, хомяк, карась, кобра, дрофа, жаворонок. соболь, бобр, красноперка, горнастай, журавль, иволга. тигр, суслик, ласка, лосось, линь, индюк, дятел*

2. Терминнарның тәрҗемә вариантын дөрес итеп урнаштырыгыз:

*Малек – карабүрек* *Снегирь – керәшә*

*Стриж – шәүлегән* *Бегемот – маймыч*

*Иволга – кыр кәҗәсе* *Антилопа – су сыеры*

3. Биологик терминнарның русча вариантларын язып чыгыгыз:

*Нарат гөмбәсе, майлы гөмбә, кәстәнә, күгән, тузганак, умырзая, зирек, дәфнә, меңьяфрак*

Телне өйрәнү барышында әлеге телдә сөйләшүче җирле халыкның милли мәдәнияте, сәнгатен өйрәнүгә дә зур урын бирелергә тиеш. Милли

мәдәниятнең иң югары казанышын халык авыз иҗаты әсәрләре тәшкил итә. Халык авыз иҗатының педагогик функцияләре турында күп санлы хезмәтләр язылды. Ә менә телгә өйрәтүгә караган методик хезмәтләрдә аларга игътибар җитенкерәп бетми кебек. Моңа кадәр бары тик татар теленең грамматик нигезләрен генә үзләштергән һәм монологлар төзергә өйрәнеп баручы балаларны татар сүз сәнгатенең асыл мәгънәсенә төшендерү телгә өйрәтүнең тагын бер бурычларыннан санала. “Биология” белгечлеген үзләштерүче студентарны халык авыз иҗатының үсемлекләр, кош-кортлар, киек-җанварлар белән бәйле булган күптөрле жанрлары(мәкаль-әйтемнәр, легенда-риваятьләр, юрамыш-сынамышлар, табышмаклар, һ.б.) белән таныштырырга мөмкин. Мәсәлән, халык авыз иҗатының афористик жанрларыннан саналган сынамышлар белән төрле биремнәр тәкъдим итәргә була.

Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.

Акчарлак килгәч, елгаларда боз тиз кузгалыр.

Апрель аеда торна кычкырса, ел яхшы килә.

Әгәр кырмыска биек түмгәк ясаса, кыш суык килер.

Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.

Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була.

Татар халык авыз иҗатында бөҗәкләр, сөйрәлүчеләр, җир-су хайваннары, кош-корт, җәнлекләр, йорт хайваннары турында табышмаклар бихисап. Телне өйрәтүдә алардан да мул файдаланырга мөмкин.

Җәйнең буе бал җыя, кышның буе хәл җыя.

Тызлый да бызлый, үпкән җире сызлый (бал корты).

Ни кош түгел, ни корт түгел, тезе билдән югары(чикерткә).

Энәләре үзе белән йөри,

Үзе тегә белми (керпе).

Әлбәттә, телгә өйрәтү барышында, татар халык иҗаты белән кызыксындыру өчен, укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүе, аның иҗади эшләү күнекмәләренә ия булуы таләп ителә. Эш барышында эстетик принцип (татар теленең матурлыгын күрә, тоя белүе), эзлеклелек принцибы (укучы алган белемнең даими рәвештә тулылана, байый баруы), укучыларның телне белү дәрәҗәсен искә алып эш итү мөһим.

Телгә өйрәтү дәресләрендә укучыларда аралашу ихтыяҗы булдырыла, аның ярдәмендә һөнәри һәм гомуммәдәни әһәмиятле мәгълүмат алу теләген уяту бурычы куела. Аралашу өчен сайлап алынган теманың студент сайлаган һөнәр белән бәйле булуы мөһим, чөнки студент югары һөнәри белем бирү уку йортына билгеле бер һөнәр үзләштерү өчен укырга керә һәм булачак һөнәре

белән бәйле теләсә нинди мәгълүмат анда кызыксыну уятырга сәләтле. Шулай итеп, һөнәри белем бирү уку йортларының төп бурычы студентны теге яки бу белгечлеккә өйрәтүдә генә түгел, бәлки әлеге һөнәрне нигезле үзләштереп, икетеллелек шартларында үзе сайлаган өлкәдә төпле, иҗади эшләвенә ирешүдән гыйбарәт.

Әдәбият


1. Татарча-русча сүзлек. – М.: Сов. энциклопедия, 1966.– 836 б.
2.Татарча-русча уку-укыту сүзлеге. – М.: Рус теле, 1991.– 416 б.
3. Татар халык иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– 592 б.
4. Татар халык табышмаклары. Җыючысы һәм төзүчесе Н.Исәнбәт. К., 1970. – 479 б.